**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УЫУССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 28**

Уруссу штп «26» 10 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 15.08.2023 № 15 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итү тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР КАБУЛ ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 15.08.2023 № 15 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибе һәм сроклары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 8.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.4. Мөрәҗәгатькә җавап электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яисә гражданның Бердәм порталдагы шәхси кабинетының адресы (уникаль идентификаторы) буенча һәм язма рәвештә, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма рәвештә мөрәҗәгать иткән почта адресы буенча җибәрелә. Моннан тыш, тәкъдим, гариза яисә шикаять булган, билгесез затлар даирәсе мәнфәгатьләренә кагыла торган җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгатькә, аерым алганда, билгесез затлар даирәсенә карата чыгарылган суд карарына шикаять бирелә торган мөрәҗәгатькә җавап, шул исәптән суд карарына шикаять бирү тәртибен аңлатуга бәйле рәвештә, Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлеше һәм Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлеше таләпләре үтәлеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга мөмкин.».

1.2. Нигезләмәнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Электрон документ рәвешендә җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка кергән мөрәҗәгать Федераль законда һәм Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Мөрәҗәгатьтә граждан үзенең фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы - булган очракта) мәҗбүри рәвештә күрсәтә, шулай ук электрон почта адресын күрсәтә йә Бердәм порталда шәхси кабинетның адресын (уникаль идентификатор) файдалана, аның буенча җавап, мөрәҗәгатьне яңадан адреслау турында хәбәрнамә җибәрелергә тиеш. Граждан мондый мөрәҗәгатькә кирәкле документларны һәм материалларны электрон формада кушып бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Урыссу шәһәр тибындагы
поселогы башлыгы, Совет рәисе А.Ә. Шәфигуллин